ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» октябрь 2022 ел № 245

2022 елга Әгерҗе муниципаль районында гражданнарның кереме күләменең һәм аларның мөлкәте хакының аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында салым салынырга тиешле хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 17 декабрендәге 955/пр номерлы «2022 елның беренче яртыеллыгына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры бәясе нормативы турында Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясенең 2022 елның I кварталына күрсәткечләре хакында» һәм 2022 елның 29 мартындагы 215/пр номерлы "Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2022 елның II кварталына уртача базар хакы күрсәткечләре турында", муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын, аларны аз керемлеләр дип тану һәм аларга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү максатларында, әлеге карарның 2 пункты нигезендә исәпләнгән керем күләмен билгеләргә:

1.1. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга кеременең чик әһәмияте 15 569,46 сум күләмендә;

1.2. салым салынырга тиешле гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакының иң чик әһәмияте:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 693 000 сум;
1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 386 000 сум;
1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 079 000 сум;
1.2.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 772 000 сум;
1.2.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 5 032 260 сум;
1.2.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 3 465 000 сум;
1.2.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 851 000 сум;
1.2.8. сигез кешедән торган гаилә өчен – 5 544 000 сум.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен билгеләү методикасын һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм Әгерҗе муниципаль районында салым салынырга тиешле мөлкәт хакын 2022 елга расларга.

3. Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте һәм торак-коммуналь хуҗалыгы Секторына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 бүлекләрендә күрсәтелгән чик күрсәткечләрдән файдалануны, гражданнарны аз керемлеләр дип таныганда һәм аларны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар исәбенә куйганда, торак шартларын яхшыртканда файдаланырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.01.2022 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты карарын үз көчен югалткан дип танырга:

2022 елның 27 апрелендәге 101 номерлы карары «2022 елга Әгерҗе муниципаль районында социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның кереме һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәтләре хакының чик күрсәткечләрен раслау турында».

6. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz/tatarstan/ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan/ru).

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә. Фатыйховка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**